ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 68 от «19» 02 2021 г.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча эшче төркем турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июлендәге № 172-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 февралендәге 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча эшче төркем турындагы нигезләмәгә (Нигезләмә – алга таба) үзгәрешләр кертергә:

Түбәндәге эчтәлекле 10 абзац өстәргә:

Эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Эшче төркем карары эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Эшче төркем утырышында кабул ителгән карарлар карар кабул ителгән көнне рәислек итүче имзалаган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000010770